ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20.09.2023 с.Старое Дрожжаное № 373

2024 елга Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының балаларга сәнгать-эстетик юнәлештәге өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 14 декабрендәге 854 номерлы «Татарстан Республикасы балаларга сәнгать-эстетик юнәлештәге өстәмә белем бирү учреждениеләрен норматив финанслауны кертү турында» карары һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2024 елга кушымтада бирелгән түбәндәгеләрне расларга:

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының балаларга сәнгать-эстетик юнәлештәге өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә кушымта итеп бирелә торган норматив чыгымнарны;

балаларга сәнгать-эстетик юнәлештәге өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарга карата 0,65 күләмендә төзәтмәләр коэффициенты.

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының финанс-бюджет палатасында әлеге карарның 1 пунктында расланган норматив чыгымнар нигезендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карар Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында рәсми басылып чыгарга һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.Ф. Җәләловка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.И. Мөхәммәтҗанов

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының
2023 елның "20" сентябрендәге
373 номерлы карары белән расланган

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының балаларга сәнгать-эстетик юнәлештәге өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР

| Өстәмә белем бирү программасының юнәлеше | Территориаль дислокация | Норматив чыгымнар (1 укучыга елына сум) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | өч еллык уку вакыты | дүрт еллык уку вакыты | биш еллык уку вакыты | җиде еллык уку вакыты | иртә һөнәри-сиональ ориентация |
| Музыкаль сәнгать | авыл җирлеге | | | 79 714 | 91 055 | 116 878 |
| Сынлы сәнгать | авыл җирлеге | | 42 126 | | 37 425 | 89 801 |
| Хореография сәнгате | авыл җирлеге | | | 88 953 | 73 250 | 268 494 |
| Гомуми эстетик сәнгать | авыл җирлеге | | | 37 395 | | |
| Фольклор сәнгате | авыл җирлеге | | | 81 803 | 78 547 | 126 162 |
| Эстрада джаз сәнгате | авыл җирлеге | 123 091 | | 118 014 | | 193 471 |
| Театр сәнгате | авыл җирлеге | 63 434 | | 59 063 | 58 977 | 88 859 |

Эшләр идарәчесе: Д.Р. Сабирзянова